Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советының егерме сигезенче утырышы

Кощаково авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

29 май, 2020 ел № 73

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 маендагы 14 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр һәм төгәлләштерүләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге советы карар чыгарды:**

1. «Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2015 елның 12 маендагы 14 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм төгәлләштерүләрне кертергә:

1.1. Карар һәм кушымта исемендә, шулай ук 1 пункт текстында «өченче чакырылыш» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Бермандатлы сайлау округлары тасвирламасын (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге Советы карарына кушымта 2015 елның 12 маендагы 14 номерлы Колай бермандатлы сайлау округларына түбәндәге йортларны кертеп төгәлләштерергә:

а) Кощаково № 1 бермандатлы сайлау округына Афанасьев, Тупыл, Табачников урамнарын.

б) Кощаково № 5 бермандатлы сайлау округына Комсомол урамы буенча 2А, 43, 45, 47, 49, 51 йортлар.

в) Кощаково № 6 бермандатлы сайлау округына:

- Яшьләр урамы буенча 19 нчы йорт;
- Елга арты, Валиев урамнары.

г) Кощаково № 8 бермандатлы сайлау округына түбәндәге урамнарны: Яшьлек, Лазурная, Сафари, Җиңүгә 70 ел, Полимэкс.

д) Кощаково № 10 бермандатлы сайлау округына түбәндәге урамнарны: Күләгәле, Ылыслы, Земляничная, Каенлы, Урман арты, Кедр, Нарат.

1.3. Кощак № 7 бермандатлы сайлау округындагы «Яшьләр урамы буенча 2, 4, 6, 8, 10, 12, 14, 16, 18, 20, 22, 24 йортлар» сүзләрен « Яшьләр урамы буенча 2 – 24 йортлар » сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова